УДК 792.09

*Е.Н. Шевченко*

# КОКИ МИТАНИНЫҢ «КӨЛКЕ АКАДЕМИЯСЕ» АЙДАР ҖӘББАРОВ КУЕЛЫШЫНДА

Статья посвящена спектаклю «Пепел» Татарского государственного академического театра им. Г. Камала по пьесе Коки Митани «Академия смеха» в постановке Айдара Заббарова. Остроумная пьеса японского драматурга о комическом поединке Автора и Цензора становится для режиссера поводом для серьезного разговора на тему «художник и власть». Он включает в ткань спектакля документальный материал, связанный с трагической судьбой татарской литературы. В результате постановка Айдара Заббарова оборачивается страстным реквиемом по репрессированным татарским писателям, их уничтоженным или подвергшимся жёсткой цензуре произведениям. В статье анализируются характер взаимодействия режиссёра с текстом оригинала и особенности его авторского художественного высказывания.

**Ключевые слова:** Коки Митани, пьеса «Академия смеха», Айдар Заббаров, спектакль «Пепел», Татарский государственный академический театр им. Г. Камала, сценическая интерпретация, цензура, художник и власть.

This article is devoted to the play “Ashes” by the Tatar State Academic Theater named after G. Kamal based on the play by Koki Mitani “Academy of Laughter” directed by Aidar Zabbarov. A witty play by a Japanese playwright about a comic duel between an Author and a Censor becomes a reason for the director to have a serious conversation on the topic of “the artist and authority”. It includes documentary material related to the tragic fate of Tatar literature in the fabric of the play. As a result, Aidar Zabbarov’s production turns into a passionate requiem for the repressed Tatar writers, their destroyed or heavily censored works. The article analyzes the nature of the director’s interaction with the original text and the features of his scenic interpretation.

**Keywords:** Koki Mitani, the play “Academy of Laughter”, Aidar Zabbarov, the play “Ashes”, Tatar State Academic Theater named after G. Kamal, scenic interpretation, censorship, artist and authority.

Айдар Җәббаров (1991) – яшь булуына карамастан, инде танылып өлгергән режиссёр. Ул – Фәрит Бикчәнтәев һәм Сергей Женовачның шәкерте, бүген – Татарстан театрларында һәм республикадан читтә уңышлы эшләп килүче, күренекле режиссёр.

Татар халкының үткәне һәм бүгенгесе белән бәйле әһәмиятле тема һәм проблемалар Җәббаровның спектакльләрендә еш кына сәнгати тикшеренү объекты булып тора. Мәсәлән, Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында куелган «Хуш, авылым» (2020) һәм «Хуш, авылым. Хыял» (2021) дилогиясе татар авылының юкка чыга баруы проблемасына багышланган. Әлмәт татар драма театрында Гаяз Исхакыйның «Ул әле өйләнмәгән иде» повесте буенча куелган

спектакльдә режиссёрны милләтара никахлар мәсьәләсе кызыксындыра. «Казанга Тукай кайткан» (2024) һәм «Әлфия Авзалова. Мәңгелек юл» (2025) спектакльләрендә Камал театрында режиссёр үзе һәм тамашачы өчен татар мәдәниятенең күренекле вәкилләре образларын яңадан «ачарга» омтыла.

А. Җәббаровның япон драматургы, актёр һәм сценарист Коки Митаниның «Көлке академиясе» («Академия смеха») пьесасы буенча куелган «Көл» спектакле дә – шундый ук сәнгати тикшерену үрнәге. Биредә режиссёрның игътибар үзәгендә «рәссам һәм хакимият» темасы.

Пьесадагы вакыйгалар сугыш вакытында ниндидер уйлап чыгарылган илдә бара. «Көлке академиясе» – үзенең даими авторы (драматург-комедиографы) булган театр труппасының исеме. Ул, яңа пьеса куйганда, һәрвакыт цензураның рөхсәтен алырга тиеш. Шул ук вакытта Цензор – сәнгатьтән ерак, театрда бернәрсә дә аңламый торган һәм өстәвенә юмор хисеннән бөтенләй мәхрүм кеше. Әгәр көченнән килсә, ул авыр сугыш елларында илдә комедияләр куюны һәм, гомумән, театрларны тыяр иде. Драматург һәм Цензорның үзара мөнәсәбәтләре пьесаның эчтәлеген тәшкил итә дә.

Шулай итеп, Автор яңа комедия куярга рөхсәт алу өчен, Цензор янына килә. Цензор, пьесага «ышанычлы» төс бирергә тырышып, Авторга төзәтмә арты төзәтмә кертә. Автор шаярта, ялагайлана, текстка берсеннән-берсе мәгънәсезрәк үзгәрешләр кертеп, буйсынган булып кылана. «Как дотла гореть, спроси у пепла» рецензиясе авторы Ольга Кручина билгеләп үткәнчә, «в предлагаемых обстоятельствах конформизм Автора – это единственная доступная ему форма протеста» [2]. Шул ук вакытта ул үзен газаплаучыны уйларында юк итә.

Әмма нәтиҗәдә, парадоксаль рәвештә, комедия көлкеле төс ала һәм камилләшә бара. Башка, тагын бер көтелмәгән метаморфоза килеп туа. Комедия иҗат итү барышында Цензор калын тиреле, тупас түрәдән иҗат шатлыгын татыган псевдо-язучыга – Драматургның автордашына әйләнә.

Драматург (Эмиль Талипов) мәгънәсез салам чәчле сәер шамакай сыйфатында тәкъдим ителә. Спектакль аның stand-up стилендәге монологы белән башлана, анда ул тамашачыга бик күңелле итеп: «Хәлләр ничек, сокамерник?» – дип эндәшә, алга таба: «Ә сез безнең илдә көлүне тыюлары турында ишеттегезме?» – дип хәбәр итә. Әлеге шамакай битлеген ул спектакльнең финалына кадәр саклый.

Ә Цензор (Алмаз Борһанов) исә – үрмәкүчне хәтерләткән, кара башлык кигән бөкре сәер җан иясе образында. Митаниның сәнгати дөньясын үзенчәлекле иткән абсурд стихиясендә актёрлар икесе дә табигый рәвештә яшиләр.

Сценография (авторы Айдар Җәббаров үзе) гади, шул ук вакытта бик тә тәэсирле: Цензор кабинеты диварында стеллаж бар,

тартмалардан кирәкле кулъязмаларны алганда, аның хәрәкәте үрмәкүчнеке сыман җитез; кәгазь турагыч аппарат (шредер) һәм туралган кәгазь таулары, алар, кар көртләре кебек, сәхнәне акрынлап күмеп китә – күпсанлы әсәрләрнең язмышы әнә шундый. Ике персонажның каршылыгы, скетчны хәтерләтеп, шушы фонда бара.

«Коки Митани» әлеге пьесасын 1996 елда яза, һәм аның бай сәхнә тарихы бар. Ул Россиядә бик популяр. Аны Пушкин исемендәге театр (реж. Роман Козак), Васильевскидагы театр (реж. Владимир Петров), Ленсовет исемендәге театр (реж. Фёдор Пшеничный), Евгений Вахтангов исемендәге театр (реж. Изабелла Каргинова), Воронеждагы «Прогресс» арт-үзәге (реж. Михаил Бычков) һ. б. куя. Кагыйдә буларак, Коки Митани әсәрләре алар тарафыннан комик, гротеск-абсурд юнәлештә хәл ителә.

Күрәсең, Айдар Җәббаровны да япон драматургы текстының сәхнә өчен яраклы булуы һәм иронриясенең шәплеге җәлеп иткәндер. Әмма ул үткен сүзле скетч белән генә чикләнмәгән. Алай гына да түгел, көлке пьесадан ул асылы белән фаҗигалы сәнгати фикерле әсәр тудырган. Ләйсән Фәизова «Көлке һәм көл» дигән мәкаләсендә Айдар Җәббаров куелышында икеләтелгән код булуын ассызыклый һәм, әсәрнең исемен аңлатып, болай дип яза: «На татарском языке название его звучит “Көл”, что действительно переводится как “пепел”. Но это омоним, также означающий “смейся”» [3]. Режиссёр регистрларны күчерә, һәм Автор белән Цензорның комик бәхәс-көрәше цензура башбаштаклыгыннан зыян күргән бихисап иҗат әһелләренең фаҗигасына әверелә. Эмиль Талипов һәм Алмаз Борһанов һәр эпизодның ахырында, Б. Брехт алымын кулланып, рольдән чыгалар: парикларын һәм әкәмәт костюмнарын салып ташлыйлар да зал белән аралашучы замана яшьләренә әйләнеп калалар. Талипов барабаннар артына утыра, Борһанов кулына гитара ала һәм алар, бергәләп, Виктор Цой, Зөлфәт Хәким җырларын һәм Хәсән Туфанның «Агыла да болыт агыла» шигыренә язылган җырны башкаралар (музыка кораллары буенча педагог – Йосыф Бикчәнтәев). Ике төрле сәхнә чынбарлыгын берләштергән әлеге алымга күп тапкырлар мөрәҗәгать ителә. Арткы пландагы «Икенче көн», «Өченче көн» һ. б. язулар актёрларны «пьесага» кайтара. Автор һәм Цензорның бәхәс-көрәше җиде көн дәвам итә. Бу – пьесаның язылу этаплары да, дөнья яратылуга ирония булган аллюзия дә.

Ә. Җәббаров спектакльгә документаль катламны да кертеп җибәрә. Танылган театр белгече һәм театр тәнкыйтьчесе Марина Дмитревская болай дип билгели: «спектакль прошит, пропитан татарскими реалиями, фактами, аллюзиями, мемуарами, ссылками и сносками» [1].

Арткы планда цензура корбаны булган татар язучыларының исем-фамилияләре языла: Габдулла Тукай, Кәрим Тинчурин, Хәсән

Туфан, Әмирхан Еники, Гаяз Исхакый, Адлер Тимергалин. Аларның истәлек-хатирәләре яңгырый: бөтенләй язмаска уйлавы турында – Әмирхан Еники, Петербургка барып, патша цензоры Смирновны атып үтерәсе килүе турында – Гаяз Исхакый, «Китмибез!» шигырен тыйганнан соңгы эзәрлекләүләр турында – Габдулла Тукай. Адлер Тимергалин мәктәп ишегалдындагы учакта тыелган әдәбиятны ничек яндырулары һәм тиздән аңа каршы эзәрлекләүләр башлануы турында сөйли. Репрессияләнгән һәм һәлак булган, бер истәлек тә калдырмаган Кәрим Тинчурин уйлап чыгарылган монолог аша тәкъдим ителә: «Ишеттегезме тәнәфестә звонокны? “Зәңгәр шәл”дән бит ул. Минем “Зәңгәр шәл”дән. Мин язган. Сәйдәш, әй, канатланып язды инде музыкасын... Артистларны кушылып җырларга, нотага өйрәтеп азапланган иде, әй... 26 нчы ел иде ул. Премьера көнне тамашачылар ярты сәгать буе пәрдәне яптырмыйча алкышлады! Ярты сәгать. Ә унике елдан “Зәңгәр шәл” дә, башка әсәрләрем дә туракланып, көл булып күккә очты. Таа-та та-та та-таам!..»

Шулай итеп, спектакль юк ителгән кулъязмаларга реквием булып яңгырый. Алар, кызганычка каршы, янып көлгә әйләнә. Спектакльнең исеме дә шуннан алынган.

Цензор һәм Авторның үзара мөнәсәбәтләре дә көтмәгәндә тагын берничә мөһим үзгәреш кичерә. Геройлар бер-берсенең кулларын кысышкан мизгел килеп җитә, ниһаять, Автор белән Хакимият арасында компромисска ирешергә мөмкин, дигән уй туа. Әмма алдагы эпизодта ук Цензорның чын йөзе ачыла: ул сәеррәк автордаш кыяфәтеннән чыга, кара күзлеген киеп куя һәм Драматургны, дәүләт җинаятьчесе буларак, кулга алачагын белдерә. М. Дмитревская билгеләп үткәнчә, «То есть, не только Драматург придуривался и корчил смешные рожицы – паяц от власти, Цензор тоже играл все это время в свой театр, два лицедея морочили друг друга» [1].

Шулай да Цензор Драматургны кулга алмый, ул аңа: «Китә аласыз», – ди, чөнки аның беркая да барыр җире юклыгын бик яхшы белә. Сугыш бара, һәм Драматургка фронтка китәргә повестка килгән инде. Шулай булгач, Цензорга аны кулга алуның кирәге юк, болай да үтерәчәкләр. Ә «Көлке академиясе» театры белән нәрсә булыр соң? «Ул көлгә әйләнәчәк...» – дип җавап бирә Драматург. Шулай итеп, Автор белән Хакимият арасында бернинди дә татулык була алмый: берсе – иҗатчы, икенчесе – иҗатны үтерүче.

Финалда Драматург – Талипов барабаннар артына утыра һәм Хәсән Туфан сүзләренә язылган җырны башкара:

Агыла да болыт агыла
Туган-үскән җирләр ягына;
Тәрәзәгә чиртер дә яңгыр,
Нәрсә әйтер туганнарыма?!
Агыла да болыт агыла...

Сүз уңаеннан, Айдар Җәббаровның Камал театрында режиссёрлык дебюты шушы шигырь белән бәйле. 2017 елда ул театрның Кече залында Хәсән Туфанның лагерьда һәм сөргендә язылган шигырьләре буенча «Агыла да болыт агыла» дип исемләнгән диплом алды спектаклен куйды. Шигырь текстлары Туфан Миңнуллинның шагыйрьгә багышланган биографик пьесасыннан алынган күренешләр белән аралашып бара. Ул вакытта ук А. Җәббаров образларының метафораларга төренүе, режиссёрның оригиналь формаларга мөрәҗәгать итүе, телне тоемлавы һәм сүзне гармонияле рәвештә ишарә белән куша белүе театр җәмәгатьчелеген аның таланты турында сөйли башларга мәҗбүр итте. Һәм аңа татарның новатор режиссёры Д. Сираҗиев исемендәге премия бирелде.

«Көл» спектаклендә Хәсән Туфанның көйгә салынган «Агыла да болыт агыла» шигыре символик мәгънә ала: Эмиль Талипов җырны башкарган вакытта, сәхнәнең арткы планында һәлак булган татар язучылары һәм шагыйрьләренең исемлеге күренә.

М. Дмитревская Айдар Җәббаров спектакле турында уйлануларын йомгаклап, болай ди: «Сложносочиненный черно-белый спектакль Заббарова звучит яростной, обугленной песней протеста, двухчасовым поминанием всей цензурованной и уничтоженной татарской литературы, он – некролог репрессированным татарским писателям, среди которых – несомненные классики» [1].

Айдар Җәббаровның сәнгати теле турында сөйләгәндә, аның синтетик, полижанр характерында булуын билгеләп үтмәскә мөмкин түгел: анда клоунада һәм публицистика, кара комедия һәм абсурд, шигърилек һәм кырыс документ теле арасында көчле бәйләнеш күзәтелә. Күпсанлы кинореминисценцияләр («от дзеффиреллевских “Ромео и Джульетты” с музыкой Нино Роты до скандального “Джокера” Тодда Филлипса, который в свою очередь вдохновлялся фильмами Мартина Скорсезе, в частности “Королём комедии” с Робертом де Ниро» [2]) аерым игътибарга лаек.

Шул рәвешле, Айдар Җәббаров үзенең «Көл» спектаклендә, Коки Митани пьесасының оригиналь текстын үзгәртмичә диярлек, документаль материал кертү, читләштерү техникасын, жанрлар синтезы һәм башка сәнгать чаралары һәм алымнарын куллану исәбенә, үзенең авторлык фикерен формалаштыра. Ул – үз халкының язмышы белән бәйле, әмма шул ук вакытта ачык театраль формалы. Шуның белән ул яшь режиссёр иҗатының гомуми контекстына табигый рәвештә кереп китә дә.

**Әдәбият**

1. *Дмитревская М.* «Пепел» Айдара стучит в мое сердце» // URL: https://ptj.spb.ru/blog/pepel-ajdara-stuchit-v-moe-serdce/?ysclid=m563e6u41g253596752 (дата обращения: 18.01.2025).

2. *Кручина О.* Как дотла сгореть, спроси у пепла // URL: https://rt-online.ru/kak-dotla-goret-sprosi-u-pepla/ (дата обращения: 10.01.2025).

3. *Фаизова Л.* Смех и пепел // URL: https://ptj.spb.ru/archive/110/process-110/smex-i-pepel/ (дата обращения: 16.01.2025).

4. *Хабутдинова М.М.* «Возвращение слова Тукая» на казанскую сцену первой четверти XXI в.: открытия и находки // Зрелищные искусства: контакты и контексты: материалы II Междунар. науч.-практ. конф., посвящ. 90-летию со дня рождения Марселя Салимжанова и 100-летнему юбилею Анаса Тумашева / сост. и науч. ред. Р.Р. Султановой. Казань: ИЯЛИ, 2024. С. 34–45.

***Шевченко Елена Николаевна,***
*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Сәнгать белеме үзәге өлкән фәнни хезмәткәре*

***Шевченко Елена Николаевна,***
*кандидат филологических наук, старший научный сотрудник Центра искусствоведения Института языка, литературы и искусства имени Г. Ибрагимова АН РТ*
*elenachev@inbox.ru*